ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ЯДЫГЕРЬСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

# КАРАР

2022 елның 25 октябре №27

Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендә кабул ителгән 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык (волонтерлык) турында «Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 340-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Ядегәр авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендә кабул ителгән 18 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктында:

1) дүртенче абзацта «күрсәтүнең» сүзен гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдә, янгыннарны кисәтүдә һәм сүндерүдә, һәлакәттән коткару эшләрендә катнашу, шулай ук күрсәтүнең» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«гражданнарның хәбәрсез югалган затларны эзләүдә катнашуы».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Башкарма комитет җитәкчесе: А.Н.Фәйзуллин